Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авылы
җирлеге башкарма комитеты

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк
авылы, Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» май 2020 ел №2

Җир кишәрлегеннән файдаланунын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча рөхсәт бирү мәсьәләләренә карата Илбәк авыл җирлеге халкының фикерен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатыннан, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, Илбәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, **карар бирәм:**

1. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

1.1. 16:02:250101:345 кадастр номерлы 173 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 53А йорты адресы буенча урнашкан - фельдшер-акушерлык пунктлары - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – Илбәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча комиссиясе;

- үткәрү вакыты –2020 елның 04 июненнән 2020 елның 06 июленә кадәр 17.00 сәг тән 18.00 сәг кә кадәр;

- үткәрү урыны – Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 50 йорт адресы буенча урнашкан Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча 2020 елның 04 июленә кадәр язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес: Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 53 йорт, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты дип билгеләргә.

3. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре проектын әзерләү буенча комиссиясенә:

- 2020 елның 04 июненә кадәр, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт соралучы җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир

кишәрлекләренә ия булучыларга, җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар билгеләнү турында хәбәр бирергә;

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төре буенча рөхсәт бирү буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарарга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru// урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина